ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.05.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1329**

«Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 05 маендагы 1167 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль закон нигезендә муниципаль маршрутлар буенча көйләнмәгән тарифлар һәм тиешле маршрут карталары буенча даими ташуларны гамәлгә ашыру турында таныклыклар алу хокукына ачык конкурслар уздырылуга бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 05 маендагы 1167 номерлы карары белән расланган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестрына, әлеге карарга кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) рәсми сайтында урнаштырырга
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. О. Котельниковка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин